ГЛАВА КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.16, с. Кильдеево,
422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 16 нче йорт, Килди авылы,
422586

Тел.: (84379) 34-7-41, факс: (84379) 34-7-41.

21.10.2020 № 3

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Уланово авылында халык җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уланово авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021нче елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме? - Уланово авылы су башнясының беренче санитар зонасын төзекләндерү мәсьәләлере буенча 2020нче елның 21нче октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 78 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 40 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 40 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегенең Уланово авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип табылды.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлегенең Уланово авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары карары белән билгеләнгән ташламалы категориядән тыш, һәр балигъ булган кешедән 2021нче елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү – Уланово авылындагы су башнясының беренче санитар зонасын төзекләндерү мәсьәләләре буенча карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлегенең Уланово авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Килди авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В. М. Бурдин